# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОШТАУЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

16 январь 2019 ел №1

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федраль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге уставына нигезләнеп Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның әлеге тәртибен расларга (1 нче кушымта).

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Коштаулы авыл**
**җирлеге башлыгы** **Сабиров Х.Ф.**

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы
Коштаулы авыл җирлеге
башкарма комитетының
16.01 2019 елның 1
номерлы карарына 1 нче
кушымта

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1.Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 18 яшькә җиткән һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан 2019 елның 31 мартына кадәр вакытка, гражданнарның түбәндәге категорияләреннән тыш, көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскадагы инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, күп балалы гаиләләрдән тыш, аларның җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашу-катнашмавына һәм аларның тавыш бирү барышында белдергән мөнәсәбәтләреннән бәйсез рәвештә түләнә.

3. Җитди сәбәпләр булганда, алар булырга мөмкин:

а) авыру,

б) озын командировкалар,

в) табигый бәла-каза, янгын нәтиҗәсендә зыян килү,

гражданнарга гариза нигезендә өч айдан артык булмаган вакытка, түләү кертүне кичектереп тору рөхсәт ителергә мөмкин,

ә түбәндәге гадәттән тыш очракларда:

а) авыр формадагы авыру,

алты айдан артык булмаган вакытка түләү кертүне кичектереп тору рөхсәт ителергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләнә торган түләүне башкару турындагы белдерү кәгазе бланкы гражданнар игътибарына Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә, муниципаль хокукый актларны халыкка игълан итү өчен муниципаль берәмлек Уставының билгеләнгән тәртибе нигезендә бастырып чыгару ,шулай ук имза куйдырып шәхсән тапшыру яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Белдерү кәгазе үз эченә гражданнарның үзара салым акчаларын түләү реквизитларын, бер тапкыр түләнә торган акчаның тулысынча яки киметелгән күләмдәге суммасын, түләү вакытын алырга тиеш.

5. Гражданнардан алынган үзара салым акчалары Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге башкарма комитеты лицевой счетына

күчереләләр.

6. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге башкарма комитеты аша күчерү яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

7. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

8. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы
Коштаулы авыл җирлеге
башкарма комитетының
16.01 2019 елның 1
номерлы карарына 2 нче
кушымта

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү кертү турында
БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ № _______________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
__________________________________________________________________________
Адрес: ____________________________________________________________
Нигезләмә ________________________________________________________
Сезгә _______________________ көнгә кадәрге вакыт эчендә
_____________________________________________________ чараны гамәлгә ашыру
буенча _____________ сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләүне түбәндәге реквизитларга күчерергә кирәк:
Кабул итүче як банкы БИК ______________________________________
Сч. № __________________________________
Кабул итеп алучы Сч. № __________________________________________
ИНН __________________________________________
КПП __________________________________________
КБК _______________ ОКАТО ___________________
Түләүнең билгеләнеше

Авыл җирлеге башлыгы___________ /_______________________________________/
М.У. (имза) (тулысынча язылыш)
\- - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисеп алу сызыгы** - - - - - - - - - - - - - -
Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүнең _____ сум күләмендә түләү турында № ________ белдерү кәгазе.
Түләүченең Ф.И.Ә.и. ________________________________________________________
Адрес:
__________________________________________________________________________
Кабул ителде «__» _______________ 20__ ел.
_______________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, түләү кәгазе өлеше (отрывной корешок) тутырыла һәм ______________ җирлеге башкарма комитетында кала.*